Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

25.08.2020 Менделеевск ш. №270

Татарстан АССРның 100 еллыгы:
тарих һәм хәзерге заман

Менделеевск муниципаль районы башлыгы В.С.Чершинцев докладын тыңлап фикер алышканнан соң,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. “Татарстан АССРның 100 еллыгы: тарих һәм хәзерге заман” докладын игътибарга алырга.

2. Менделеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарына, муниципаль учреждениеләргә һәм оешмаларга тәкъдим итәргә:

- инициативаны хупларга һәм ТАССР төзелүнең 100 еллыгына багышланган республика һәм район чараларында катнашырга;
- республика тарихының данлыклы битләрен һәм вакыйгаларын мәңгеләштерү, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм социаль челтәрләрдә киң яктыртылып үсүгә зур өлеш керткән ТАССР эшлеклеләре, ветераннар истәлеген саклау буенча комплекслы эшне дәвам итәргә;
- республиканың күренекле казанышларын пропагандаларга, шул исәптән яшь буын арасында районда да;
- Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен һәм мәдәниятен, татар телен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә ярдәм итәргә.

3. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет Рәисе В.С.Чершинцев